КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 11 сентябрь г.Казань № 857

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 ел, 27 август, 616 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 ел, 27 август, 616 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 31 март, 200 нче; 2021 ел, 3 июль, 541 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2.1 пунктта:

дүртенче абзацта «төзелә (проектлана) торган индустриаль (сәнәгать) паркның» сүзләрен төшереп калдырырга;

җиденче абзацта «яки төзелә (проектлана) торган индустриаль (сәнәгать) парк» сүзләрен төшереп калдырырга;

сигезенче абзацта «яки төзелә (проектлана) торган индустриаль (сәнәгать) парк» сүзләрен төшереп калдырырга;

унынчы абзацта «(төзелә торган индустриаль (сәнәгать) парклар өчен)» сүзләрен төшереп калдырырга;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«булган резидентлар һәм идарә итүче компания арасында индустриаль (сәнәгать) парк территориясендә эшчәнлек алып бару турында гамәлдәге килешүләр (шартнамәләр) һәм (яки) индустриаль (сәнәгать) парк территориясендә эшчәнлек алып бару ниятләре турында гамәлдәге килешүләр;»;

2.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Заявка вәкаләтле оешмага кәгазьдә һәм электрон мәгълүматлар йөртү җайланмасында сканерланган рәвештә бирелә»;

3.1 пунктта:

«а» пунктчасында «, төзелә (проектлана) торган индустриаль (сәнәгать) паркның» сүзләрен төшереп калдырырга;

«б» пунктчасының беренче абзацында «, төзелә (проектлана) торган индустриаль (сәнәгать) паркның» сүзләрен төшереп калдырырга;

«в» пунктчасының беренче абзацында «, төзелә (проектлана) торган индустриаль (сәнәгать) паркның» сүзләрен төшереп калдырырга;

«в» пунктчасының өченче абзацында «, төзелә (проектлана) торган индустриаль (сәнәгать) паркның» сүзләрен төшереп калдырырга;

«д» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

«е» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«парк территориясендә кулланучыларны электр энергиясенә тоташтыру ноктасы булу, яки кулланучыларны электр энергиясенә технологик тоташтыруга гамәлдәге техник шартлар булу, яки электр энергиясен җитештерү буенча үз объектлары булу, яки электр энергиясен җитештерү буенча үз объектларын төзүнең билгеләнгән тәртиптә килештерелгән проекты һәм кулланучыларны электр энергиясенә технологик тоташтыруга техник шартлар булу;»;

«ж» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

4.3 пунктта:

икенче абзацта «, төзелә (проектлана) торган индустриаль (сәнәгать) паркның» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «, төзелә (проектлана) торган индустриаль (сәнәгать) паркның» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымтада «(төзелә торган булса, паркның төрен күрсәтергә)» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин